# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Хәрабә хәлендәге торакларны бетерү
<u>өчен максатчыл салым турында"</u>

Максатчыл салым кертүнең максаты хәрабә хәлендәге торак фондын бетерү, хәрабә хәлендәге торак кварталларын үзгәртеп кору өчен өстәмә финанс ресурслары булдырудан гыйбарәт.

<u>1 статья.</u> Салым түләүчеләр

Хокукый затлар булучы, эшкуарлык эшчәнлеген башкаручы предприятиеләр, учреждениеләр (банкларны һәм башка кредит учреждениеләрен дә кертеп) һәм оешмалар, шул исәптән чит ил инвестицияләре белән эшләүче предприятиеләр дә, әлеге Закон нигезендә салым түләүчеләр булалар.

<u>2 статья.</u> Салым салынучы объект һәм салым исәпләү ставкасы

Сатылган продукциянең (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) күләме салым салынучы объект була.

Хәрабә хәлендәге торакларны бетерү өчен салым түбәндәге ставка буенча билгеләнә:

Татарстан Республикасының әлеге Законын гамәлгә керткән көннән башлап 1997 елның 1 гыйнварена кадәр 0,3 процент;

1997 елның 1 гыйнвареннан 0,6 процент.

95



3 статья. Салым буенча ташламалар

Салым түләүдән түбәндәгеләр азат ителә:

алынган табышының кимендә яртысы гарипләрнең социаль ихтыяҗларына тотылганда, хезмәткәрләренең гомуми санынннан кимендә 50 проценты гариплар яисә кимендә 70 проценты гариплар һәм пенсионерлар булган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар;

халыкка ритуаль хезмәт күрсәтүче һәм башкарылган эшләренең гомуми күләмендә әлеге хезмәтләрнең күләме кимендә 70 процент булган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар;

Бөек Ватан сугышы инвалидларының, анда катнашучыларның һәм аларга тиңләштерелгән затларның, шул исәптән башка дәүләтләр территориясендәге хәрби гамәлләрдә катнашкан ветераннарның, Чернобыль АЭСндә һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларның җәмәгать оешмалары һәм әлеге җәмәгать оешмалары милкендәге предприятиеләр;

керемнәренең гомуми суммасында авыл хуҗалыгы продукциясен сатудан килгән керемнәрнең чагыштырма аурлыгы кимендә 70 процент булган колхозлар, совхозлар, крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясе житештерү белән шөгыльләнүче предприятиеләрнең, оешмаларның, учреждениеләрнең ярдәмче хуҗалыклары;

хуҗалык исәбендәге төзелмәләрен дә кертеп, җиназть - башкарма система органнары һәм бүлекчәләре.

4 статья. Салым исәпләү һәм түләү тәртибе

Салым, билгеләнгән ставкадан һәм продукцияне (эшләрне, хезмәтләрне) сатуның факттагы күләменнән чыгып, ай саен исәпләнә.

Салым ай саен салым түләүчеләр тарафыннан Татарстан Республикасының Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына кертелә.

Салым түләү чыгымнары сатылган продукция (эшләр, хезмәт

96



күрсәтүләр) үзкыйммәтенә кертелә.

5 статья. Салым түләүчеләрнең җаваплылыгы һәм салым органнарының тикшереп торуы

Татарстан Республикасының Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына кертелүче максатчыл салымны исәпләүнең дөреслеге, тулысынча һәм вакытында кертелүе өчен җаваплылык салым законнары нигезендә түләүчеләргә йөкләнә.

Салым исәпләүнең дөреслеген Татарстан Республикасының Бюджеттан тыш дәүләт торак фондының башкарма дирекциясе һәм салым органнары тикшереп тора.

6 статья. Әлеге Законны куллану буенча күрсәтмә

Әлеге Законны куллану буенча күрсәтмә, Татарстан Республикасының Финанслар министрлыгы белән килешенеп, Татарстан Республикасы буенча Дәүләт салым инспекциясе тарафыннан бастырып чыгарыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 13 июне
N 648